**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.32, село Черемшан,423100

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 32ейорт, Чирмешәнавылы, 423100

тел.+7(84396) 2-58-00 тел./факс +7(84396) 2-58-42,email:Ispolkom.Cheremshan@tatar.ru; http://cheremshan.tatarstan.ru

19.03.2020 ел № 106

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **Чирмешән авылы** **КАРАР**

Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген түләүсез милеккә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген түләүсез милеккә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын яңа редакциядә кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru).
3. ТР Чирмешән муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына биш эш көне дәвамында әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуда җаваплылыкны үз өстемә алам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе И.Н. Шәйдуллин

Татарстан Республикасы Чирмешән
муниципаль районы Башкарма
комитеты карарына
кушымта
19.03.2020 ел, №106

## Муниципаль милектәге җир кишәрлеген милеккә бушлай бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты

### 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Регламент) муниципаль милектәге җир кишәрлеген милеккә бушлай бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү стандартын һәм тәртибен (алга таба – муниципаль хезмәт) билгели.

1.2. Муниципаль хезмәт алучылар (алга таба - мөрәҗәгать итүче): Россия Федерациясе Җир кодексының 39.5 статьясында күрсәтелгән органнар һәм учреждениеләр (1нче кушымта).

1.3. Муниципаль хезмәт Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы (алга таба – Палата) тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Палатаның урнашу урыны: шәһәр тибындагы бистә (ав.) Чирмешән, М. Титов ур., 26нчы йорт.

Эш графигы:

дүшәмбе-җомга: 8.00дән 17.00гә кадәр;

шимбә, якшәмбе: ял көннәре;

Ял һәм туклану өчен тәнәфес вакыты эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре белән билгеләнә.

Белешмә телефоны: (84393) 2-57-11.

Шәхесне раслаучы документлар буенча узу.

1.3.2. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – «Интернет» челтәре) муниципаль районның рәсми сайты адресы: cheremshan.tatarstan.ru.

1.3.3. Муниципаль хезмәт, шулай ук Палатаның урнашу урыны һәм эш графигы турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) Палата биналарында урнашкан муниципаль хезмәт турында визуаль һәм текст мәгълүматларын үз эченә алган мәгълүмати стендлар ярдәмендә, гариза бирүчеләр белән эшләү өчен.

Татарстан Республикасының дәүләт телләрендәге мәгълүмат әлеге Регламентның 1.1, 1.3.1, 2.3, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларда (пунктчаларда) булган муниципаль хезмәт турында белешмәләрне үз эченә ала;

2) «Интернет» челтәре аша муниципаль районның рәсми сайтында cheremshan.tatarstan.ru

3) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталында (http://uslugi. tatar.ru/);

4) Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталында (http:// www.gosuslugi.ru/);

5) Палатада:

телдән мөрәҗәгать иткәндә - шәхсән яки телефон буенча;

язма (шул исәптән электрон документ формасында) мөрәҗәгать иткәндә – кәгазьдә почта аша, электрон формада - электрон почта аша.

1.3.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат Палатаның белгече тарафыннан муниципаль районның рәсми сайтында һәм Палата бинасындагы гариза бирүчеләр белән эшләү өчен мәгълүмат стендларында урнаштырыла.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

1994 елның 30 ноябрендәге 51-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Граждан кодексы (алга таба – РФ ГК) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 05.12.1994, № 32, 3301 ст.);

2001 елның 25 октябрендәге 136-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Җир кодексы (алга таба – РФ Җир кодексы) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 29.10.2001, №44, 4147 ст.);

«Мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (шәхси) исәпкә алу турында» 1996 елның 1 апрелендәге 27-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 27-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ законнары җыелмасы 01.04.1996, №14, 1401 ст.);

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 131-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ законнары җыелышы, 06.10.2003, №40, 3822 ст.);

2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелышы, 02.08.2010, № 31, 4179 ст.);

Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 2014 елның 27 ноябрендәге 762 номерлы «Территориянең кадастр планында җир кишәрлегенең яки җир кишәрлекләренең урнашу схемасына һәм территориянең кадастр планында җир кишәрлегенең яки җир кишәрлекләренең урнашу схемасын электрон документ рәвешендә әзерләгәндә территориянең кадастр планында җир кишәрлегенең яки җир кишәрлекләренең урнашу схемасы форматына, территориянең кадастр планында җир кишәрлегенең яки җир кишәрлекләренең урнашу схемасын кәгазь документ рәвешендә әзерләү формасына таләпләрне раслау турында» боерыгы белән (алга таба – 762 номерлы боерык) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы http://www.pravo.gov.ru, 18.02.2015);

Россия Икътисади үсеш министрлыгының «Мөрәҗәгать итүченең сату уздырмыйча җир кишәрлеге сатып алуга хокукын раслый торган документлар

исемлеген раслау турында» 2015 елның 12 гыйнварындагы 1 нче номерлы боерыгы (алга таба 1 нче номерлы боерык) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы http://www.pravo.gov.ru, 28.02.2015);

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы законы (алга таба – 45-ЗРТ номерлы ТР Законы) (Татарстан Республикасы, № 155-156, 03.08.2004);

Чирмешән муниципаль район Советының 2010 елның 7 августындагы 191 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Уставы (алга таба – Устав);

Советның 2005 елның 30 декабрендәге 17нче номерлы Карары белән расланган, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы турында Нигезләмә (алга таба- Палата турында Нигезләмә);

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы турында Советның 2005 елның 30 декабрендәге 17 номерлы Карары белән расланган Нигезләмә (алга таба - Палата турында Нигезләмә);

Палата Рәисенең 2018 елның 28 декабрендәге 50 номерлы Боерыгы белән расланган эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре (алга таба – Кагыйдәләр).

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгенең читтән торып эш урыны – «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру Кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы муниципаль районының (шәһәр округының) шәһәр яисә авыл җирлегендә төзелгән, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

техник хата - муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка кертелгән мәгълүматларның (муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе), документлардагы мәгълүматлар нигезендә кертелгән мәгълүматларның тиешле таләпләргә туры килмәвенә китергән хата (описка, опечатка, грамматик яки арифметик хата яисә шундый хата).

Әлеге Регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза (алга таба - гариза) астында муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы сорау аңлашыла (2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 ст. 2 п.). Гариза стандарт бланкта тутырыла (2нче кушымта).

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпнең исеме | Стандартка таләпләр эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Муниципаль хезмәтнең исеме | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген милеккә бушлай бирү | ЗК РФ, Палата турында Нигезләмә. |
| 2.2. Турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче җирле үзидарә башкарма-боеру органы исеме | Палата | Палата турында Нигезләмә |
| 2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы | Җир кишәрлеген бирү турында боерык, җир кишәрлеген кабул итү-тапшыру акты<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат. | ЗК РФ |
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү кирәклеген исәпкә алып, Россия Федерациясе законнары белән туктатылу мөмкинлеге каралган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору | Гариза кергән көннән алып 12 көн[1] эчендә җир кишәрлеген милеккә тапшыру турында карарны кабул итү.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган | |

[1] Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы административ процедураларны гамәлгә ашыру өчен кирәкле минималь суммар сроктан чыгып билгеләнә. Административ процедураларның озынлыгы эш көннәрендә исәпләнә.

| | | |
|---|---|---|
| срогы, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) вакыты | | |
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен законнар яисә башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле муниципаль хезмәтләр өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрнең тулы исемлеге, аларны мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе | 1) Гариза;<br>2) Шәхесне раслаучы документлар;<br>3) Вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ (әгәр мөрәҗәгать итүче исеменнән вәкил гамәл кылса);<br>4) Җир кишәрлеген территорияләрнең кадастр планында урнаштыруның расланган схемасы (әгәр җир кишәрлеген төзергә кирәк булса һәм чикләрендә җир кишәрлеген төзү каралган территорияне межалау проекты расланмаган булса)<br>Мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирелә торган өстәмә документлар исемлеге, хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучының категориясенә карап 3нче кушымтада китерелгән.<br>Муниципаль хезмәт алу өчен гариза бланкын гариза бирүче Башкарма комитетта шәхси мөрәҗәгать иткәндә ала ала. Бланкның электрон формасы Башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм кушып бирелә торган документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:<br>шәхсән (гариза бирүче исеменнән ышаныч кәгазе нигезендә эш итүче зат);<br>почта аша җибәреп.<br>Гариза һәм документлар, шулай ук, мөрәҗәгать итүче тарафыннан гомуми файдаланудагы | 1нче номерлы боерык |

| | | |
|---|---|---|
| | мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, һәм Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы аша көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә тәкъдим ителергә (җибәрелергә) мөмкин. | |
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле һәм гариза бирүче аларны тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны бирү тәртибе;<br>карамагында әлеге документлар булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча мөрәҗәгать итүченең индивидуаль шәхси счетының иминият номеры турында белешмәләр (Россия Федерациясе Пенсия фондында), шулай ук хезмәт алучыларның категориясенә карап, 3 нче кушымта нигезендә документлар һәм белешмәләр алына.<br>Мөрәҗәгать итүче тәкъдим итәргә хокуклы документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пункты белән билгеләнгән.<br>Мөрәҗәгать итүчедән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган югарыда аталган документларны таләп итү тыела.<br>Гариза бирүченең югарыда күрсәтелгән мәгълүматларны үз эченә алган документларны тапшырмавы гариза бирүчегә хезмәт күрсәтүдән баш тартуга нигез булып тормый | 27-ФЗ номерлы Федераль закон<br><br>1нче номерлы боерык |
| 2.7. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен | 1) Тиешле булмаган зат тарафыннан документлар тапшыру;<br>2) Тапшырылган документларның әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән | |

| | | |
|---|---|---|
| нигезләрнең тулы исемлеге | документлар исемлегенә туры килмәве;<br>3) Гаризада һәм гаризага кушып бирелә торган документларда килешенмәгән төзәтүләр, аларның эчтәлеген төгәл аңлатырга мөмкинлек бирми торган җитди зыяннар бар;<br>4) Тиешсез органга документларны тапшыру | |
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Баш тарту өчен нигезләр:<br>1) җир кишәрлеге бирү турындагы гариза белән җир законнары нигезендә сату үткәрмичә җир кишәрлеге алу хокукына ия булмаган зат мөрәҗәгать итте;<br>2) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге даими (сроксыз) файдалану, түләүсез файдалану, гомерлек мирас итеп алу яки аренда хокукында бирелгән, җир кишәрлеге бирү турында гариза белән әлеге хокукларга ия булучы мөрәҗәгать иткән яки РФ Җир кодексының 39.10 статьясындагы 2 пунктының 10 пунктчасы нигезендә җир кишәрлеге бирү турында гариза биргән очраклардан тыш;<br>3) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге, гражданнар тарафыннан төзелгән коммерциячел булмаган оешмага яшелчәлек, бакчачылык, дача хуҗалыгы яисә шәхси торак төзелеше максатларында территорияне комплекслы үзләштерү өчен бирелгән, әгәр җир кишәрлеге гомуми файдаланудагы мөлкәткә керә икән, әлеге коммерцияле булмаган оешма әгъзасы яки әлеге коммерцияле булмаган оешма гариза белән | РФ Җир кодексының 39.16ст. |

| | | |
|---|---|---|
| | мөрәҗәгать итү очракларыннан тыш;<br>4) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегендә гражданнар яисә юридик затларга караган бина, корылма, төзелеп бетмәгән объект урнашкан, киләсе очраклардан тыш, әгәр җир кишәрлегендәге корылма (шул исәптән төзелеше тәмамланмаган корылма) сервитут шартларында урнаштырылса яки җир кишәрлегендә РФ Җир кодексының 39.36 статьясындагы 3 пунктында каралган объект урнашкан булса һәм бу җир участогын аның рөхсәт ителгән куллануы буенча файдалануга комачауламый, йә җир кишәрлеге бирү турында гариза белән әлеге бина, корылмалар, алардагы бүлмәләр, төзелеп бетмәгән объект милекчесе мөрәҗәгать итсә;<br>5) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегендә дәүләт яки муниципаль милектә булган бина, корылма, төзелеп бетмәгән объект урнашкан, киләсе очраклардан тыш, корылма (шул исәптән төзелеп бетмәгән корылма) сервитут шартларында җир кишәрлегендә урнашкан булса яисә җир кишәрлеген бирү турындагы гариза белән әлеге биналарның, корылмаларның, алардагы бүлмәләрнең, бу төгәлләнмәгән төзелеш объектының хокук иясе мөрәҗәгать иткән булса;<br>6) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге әйләнештән алынып яисә әйләнештә чикләнгән булып тора һәм аны бирү җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән хокукта рөхсәт ителми;<br>7) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада | |

| | | |
|---|---|---|
| | күрсәтелгән җир кишәрлеге дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен резервланган булып тора, әгәр дә мөрәҗәгать итүче җир кишәрлеген милеккә, даими (сроксыз) файдалануга бирү яки җир кишәрлеген арендага бирү, җир кишәрлеген резервлау турында карар гамәлдә булу срогыннан артыграк срокка түләүсез файдалану турындагы гариза белән мөрәҗәгать итсә, резервлау максатларында җир кишәрлеге бирү очрагыннан тыш;<br>8) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге, территорияне үстерү турында башка зат белән килешү төзелгән территория чикләрендә урнашкан, киләсе очраклардан тыш, җир кишәрлеге бирү турында гариза белән мондый җир кишәрлегендә урнашкан бина, корылма, алардагы урыннар, төгәлләнмәгән төзелеш объекты милекчесе яисә мондый җир кишәрлегенең хокук иясе мөрәҗәгать иткәндә;<br>9) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге, территорияне үстерү турында башка зат белән килешү төзелгән территория чикләрендә урнашкан, яисә җир кишәрлеге территорияне комплекслы үзләштерү турында башка зат белән шартнамә төзелгән җир кишәрлегеннән төзелгән, киләсе очраклардан тыш, мондый җир кишәрлеге федераль әһәмияттәге объектларны, региональ әһәмияттәге объектларны яисә җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән һәм мондый җир кишәрлеген бирү турындагы гариза белән күрсәтелгән объектларны төзүгә вәкаләтле зат мөрәҗәгать иткән; | |

| | | |
|---|---|---|
| | 10) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге территорияне комплексчы үзләштерү турында шартнамә яисә төзелгән территорияне үстерү турында шартнамә төзелгән җир кишәрлегеннән төзелгән, һәм территорияне планлаштыруның расланган документлары нигезендә федераль әһәмияттәге объектларны, региональ әһәмияттәге объектларны яисә җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән, киләсе очраклардан тыш, җир кишәрлеген арендага бирү турында гариза белән территорияне комплексчы үзләштерү турында шартнамә яисә төзелгән территорияне үстерү турында шартнамә төзелгән, әлеге затның күрсәтелгән объектларны төзү буенча йөкләмәсен күздә тоткан зат мөрәҗәгать иткән;<br>11) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге аукцион предметы булып тора, аны үткәрү турында белдерү РФ Җир кодексының 39.11 статьясындагы 19 пункты нигезендә урнаштырылган;<br>12) аны бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата РФ Җир кодексының 39.11 маддәсенең 4 пунктындагы 6 пунктчасында каралган аны сату буенча аукцион яки аны арендалау шартнамәсе төзү хокукына аукцион уздыру турында гариза кергән, әгәр мондый җир кишәрлеге РФ Җир кодексының 39.11 статьясындагы 4 пунктының 4 пунктчасы нигезендә төзелгән булса һәм вәкаләтле орган тарафыннан РФ Җир кодексының 39.11 статьясындагы 8 пунктында каралган нигезләр | |

| | | |
|---|---|---|
| | буенча әлеге аукционны үткәрүдән баш тарту турында карар кабул ителмәгән очракта;<br>13) аны бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата РФ Җир кодексының 39.18 статьясындагы 1 пунктының 1 пунктчасы нигезендә шәхси торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык, дача хуҗалыгы алып бару яки крестьян (фермер) хуҗалыгы эшчәнлеге алып бару өчен җир кишәрлеге бирү турында белдерү (извещение) басылып чыкты һәм урнаштырылды;<br>14) җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану, җир кишәрлеге бирү турында гаризада күрсәтелгән, мондый җир участогын куллану максатларына туры килми, расланган территорияне планлаштыру проекты нигезендә линияле объектны урнаштыру очракларыннан тыш;<br>15) сорала торган җир кишәрлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә расланган оборона һәм куркынычсызлык ихтыяҗлары өчен бирелгән һәм күрсәтелгән ихтыяҗлар өчен вакытлыча файдаланылмый торган җир кишәрлекләре исемлегенә кертелмәгән, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.10 статьясы 2 пунктының 10 пунктчасы нигезендә җир кишәрлеге бирү турында гариза бирелгән очракта;<br>16) коммерцияле булмаган оешмага гражданнар тарафыннан яшелчәлек, бакчачылык алып бару өчен төзелгән җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге мәйданы, федераль закон нигезендә билгеләнгән чик күләмнән артып китә;<br>17) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада | |

| | | |
|---|---|---|
| | күрсәтелгән җир кишәрлеге территориаль планлаштыру турында расланган документлар һәм (яки) территорияне планлаштыру документациясе нигезендә федераль әһәмияттәге объектлар, региональ әһәмияттәге объектлар, җирле әһәмияттәге объектлар урнаштыру өчен каралган һәм җир кишәрлеген бирү турында гариза белән әлеге объектларны төзергә вәкаләтле булмаган зат мөрәҗәгать иткән;<br>18) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге Россия Федерациясе дәүләт программасы, Россия Федерациясе субъектының дәүләт программасы нигезендә бина, корылма урнаштыру өчен каралган һәм җир кишәрлеген бирү турында гариза белән әлеге бинаны, корылманы төзүгә вәкаләтле булмаган зат мөрәҗәгать иткән;<br>19) белдерелгән хокуклар төренә җир кишәрлеген бирү рөхсәт ителми;<br>20) аны бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата рөхсәт ителгән файдалану төре билгеләнмәгән;<br>21) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге билгеле бер җир категориясенә кертелмәгән;<br>22) аны бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата, аны бирүне алдан килештерү турында гамәлдә булу срогы чыкмаган карар кабул ителгән һәм җир кишәрлеге бирү турындагы гариза белән әлеге карарда күрсәтелмәгән башка зат мөрәҗәгать иткән; | |

| | | |
|---|---|---|
| | 23) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен тартып алынды һәм гаризада күрсәтелгән мондый җир кишәрлеген бирү максаты мондый җир кишәрлеген алу максатларына туры килми, мондый җир кишәрлегендә урнашкан күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тануга бәйле рәвештә дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен алынган җир кишәрлекләреннән тыш;<br>24) аны бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенең чикләре «Күчемсез милекнең дәүләт кадастры турында» Федераль закон нигезендә төгәлләштерелергә тиеш;<br>25) аны бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенең мәйданы, җир кишәрлеге урнашу схемасында, территорияне межалау проектында яки урман кишәрлекләренең урнашу урыннары, чикләре, мәйданы һәм башка микъдари һәм сыйфатлы характеристикалары турында проект документациясе нигезендә төзелгән мондый җир кишәрлегенең күрсәтелгән мәйданыннан артып китә, ун проценттан артыкка | |
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасын яисә башка түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Муниципаль хезмәт бушлай бирелә | |
| 2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтүгә түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос биргәндә, муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәткә һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты | Чират булган очракта муниципаль хезмәт алуга гариза бирү - 15 минуттан да артмый.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда, чиратта максималь көтү срогы 15 минуттан артмаска тиеш | |
| 2.13. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең запросын һәм муниципаль хезмәт | Гариза кергәннән соң бер көн эчендә.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә кергән соратып алу ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә | |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне теркәү срогы һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада | | |
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтү биналарына, көтү залына, муниципаль хезмәт күрсәтү турында запросларны тутыру урыннарына, аларны тутыру үрнәкләре һәм һәр муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге булган мәгълүмат стендлары, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматларын урнаштыру һәм рәсмиләштерү, шул исәптән федераль законнар һәм инвалидларны социаль яклау турында Татарстан Республикасы законнары нигезендә инвалидлар өчен күрсәтелгән объектларның файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр | Муниципаль хезмәт янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмати стендлар белән җиһазландырылган биналарда һәм йортларда (в зданиях и помещениях) күрсәтелә.<br>Инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керә алуы тәэмин ителә (биналарга уңайлы керү-чыгу һәм алар чикләрендә күчү).<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла | |
| 2.15. Муниципаль хезмәт | Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең һәркем өчен | |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтүләрдән файдалану мөмкинлеге һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәткәндә вазыйфаи затлар белән үзара хезмәттәшлеге саны һәм аларның дәвамлылыгы, муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмати-коммуникацион технологияләрдән файдаланып, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә, җирле үзидарә органының башкарма күрсәтмә органының теләсә кайсы территориаль бүлекчәсендә муниципаль хезмәт алу мөмкинлеге йә мөмкинлеге булмау (шул исәптән тулы күләмдә), мөрәҗәгать итүченең теләге буенча (экстриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле | мөмкин булуы күрсәткечләре булып тора:<br>бинаның җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге зонасында урнашуы;<br>белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итү башкарыла торган бүлмәләр кирәкле санда булу;<br>мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендәге Палатаның мәгълүмати ресурсларында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;<br>инвалидларга башка затлар белән беррәттән хезмәт алуга комачаулаучы каршылыкларны җиңеп чыгуда ярдәм күрсәтү.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән характерлана:<br>мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү һәм бирү өчен чиратлар;<br>муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын бозу;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең мөрәҗәгать итүчеләргә карата әдәпсез, игътибарсыз мөнәсәбәтләренә карата шикаятьләр.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорату (запрос) биргәндә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда муниципаль хезмәт күрсәтүче вазыйфаи затның да, мөрәҗәгать итүченең дә бер тапкыр үзара хезмәттәшлеге күздә тотыла. | |

| | | |
|---|---|---|
| үзәкләрендә берничә дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы запрос ярдәмендә, Федераль законның 15.1 статьясында каралган (комплекслы запрос) | Хезмәттәшлек озынлыгы регламент белән билгеләнә.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан Палата сайтында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында, КФҮ (МФЦ) алынырга мөмкин.<br>Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге (алга таба – КФҮ), КФҮнең ерактан торып эш урыннары аша муниципаль хезмәт күрсәтү гамәлгә ашырылмый.<br>Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы соратып алу составында муниципаль хезмәт күрсәтелми | |
| 2.16. Башка таләпләр, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең үзенчәлекләрен исәпкә алучы (әгәр муниципаль хезмәт экстерриториаль принцип буенча бирелгән булса) һәм электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләре | Муниципаль хезмәт күрсәтүне электрон формада алу тәртибе турында консультацияне Интернет-кабул итү бүлмәсе аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша алырга мөмкин.<br>Законда муниципаль хезмәт күрсәтү турында электрон формада гариза бирү каралган булса, гариза Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша бирелә (http://uslugi. tatar.ru/) яки Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы аша (http:// www.gosuslugi.ru/) | |

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм башкару сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон формада административ процедураларны башкару үзенчәлекләре

3.1. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә хәрәкәт тәртибен тасвирлау

3.1.1. Муниципаль хезмәтне күрсәтү үз эченә түбәндәге процедураларны ала:
1) мөрәҗәгать итүчегә консультация үткәрү;
2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;
3) муниципаль хезмәтне күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратуларны (запросы) формалаштыру һәм җибәрү;
4) муниципаль хезмәтнең нәтиҗәсен әзерләү;
5) мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәтнең нәтиҗәсен тапшыру.

3.2. Мөрәҗәгать итүчегә консультация үткәрү

3.2.1. Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт алу тәртибе турында консультацияне алу өчен Палатага шәхсән, телефон аша һәм (яисә) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

Палата белгече мөрәҗәгать итүчегә консультацияләр бирә, шул исәптән, муниципаль хезмәт алу өчен бирелә торган документларның составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча һәм кирәк булганда гариза бланкын тутыруда ярдәм күрсәтә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документлар составы, формасы һәм рөхсәт алуның башка мәсьәләләре буенча консультацияләр.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән, ышанычлы зат яисә КФҮ аша, КФҮнең ерактан торып эш урыны аша муниципаль хезмәт күрсәтү турында язмача гариза бирә һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә документларны Палатага тапшыра.

Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза электрон формада Палатага электрон почта яки Интернет-кабул итү бүлмәсе аша җибәрелә. Электрон формада кергән гаризаны теркәү билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

3.3.2. Гаризалар кабул итүче, Палата белгече түбәндәгеләрне башкара:

мөрәҗәгать итүченең шәхесен билгеләү;

мөрәҗәгать итүченең вәкаләтләрен тикшерү (ышанычнамә буенча гамәл кылган очракта);

әлеге Регламентның 2.5 пункты белән каралган документларның барлыгын тикшерү;

бирелгән документларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерү (документларның күчермәләрен тиешенчә рәсмиләштерү, документларда өзеклекләр

(подчистка), припискалар, сызып алынган сүзләр һәм башка килешмәгән төзәтмәләр булмау).

Шелтәләр булмаган очракта Палата белгече түбәндәгеләрне башкара:

гаризаларны кабул итү һәм махсус журналда теркәү;

мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган документларның исемлеге күчермәләрен, документларны кабул итү датасы, кергәндә бирелгән номеры, муниципаль хезмәт күрсәтүнең датасы һәм вакыты турында белге белән тапшыру;

гаризаны Палата җитәкчесенә карап тикшерү өчен җибәрү.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, документларны кабул итүне алып баручы Палата белгече, мөрәҗәгать итүчегә гаризаны теркәү өчен киртәләр булу турында хәбәр итә һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлатып документларны кире кайтара.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гамәлгә ашырыла:

гаризалар һәм документлар 15 минут эчендә кабул ителә;

гаризаны гариза кергәннән соң бер көн эчендә теркәү.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза, Палата җитәкчесенә карауга җибәрелгән яки гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар.

3.3.3. Палата җитәкчесе гаризаны карый, башкаручыны билгели һәм гаризаны аңа җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгәннән соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: башкаручыга җибәрелгән гариза.

3.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара мөрәҗәгатьләрне формалаштыру һәм җибәрү

3.4.1. Палата белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә электрон формада ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алына торган документларны (белешмәләрне) бирү турында запросларны җибәрә. Документлар (белешмәләр) исемлеге хезмәт алучыларның категориясенә карап билгеләнә (3нче кушымта).

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза кергән вакыттан алып бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: хакимият органнарына җибәрелгән запрослар.

3.4.2. Белешмәләр белән тәэмин итүчеләр белгечләре, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән запрослар нигезендә, соратып алына торган документларны (мәгълүматны) тапшыралар.

Әлеге пунктча белән билгеләнгән процедуралар түбәндәге срокларда гамәлгә ашырыла:

Росреестр белгечләре җибәргән документлар (белешмәләр) буенча өч эш көненнән дә артмый;

калган тәэмин итүчеләр буенча - органга яки оешмага ведомствоара запрос килгән көннән биш көн эчендә, әгәр ведомствоара сорауга җавап әзерләү һәм

җибәрүнең башка сроклары федераль законнарда, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актларында һәм федераль законнар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында билгеләнмәсә.

Процедураларның нәтиҗәсе: Палатага җибәрелгән документлар (белешмәләр) яки баш тарту турында белдерү.

3.5. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү

3.5.1. Палата белгече алынган документлар нигезендә:

җир кишәрлеген бушлай милеккә тапшыру яки муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итә;

боерык проектын яки баш тарту турында хат проектын әзерли;

билгеләнгән тәртиптә әзерләнгән документ проектын килештерү процедурасын гамәлгә ашыра;

Палата җитәкчесенә (аның вәкаләтле затына) имза куюга боерык проектын яки баш тарту турында хатны җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар соратуларга җаваплар кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Палата җитәкчесенә (аның вәкаләтле затына) имза куюга юнәлдерелгән проектлар.

3.5.2. Палата җитәкчесе күрсәтмәне яки баш тарту турында хатны имзалый һәм теркәү өчен Палатага җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар алдагы процедураны тәмамлаганнан соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган карар яки баш тарту турында хат, теркәлүгә җибәрелгән.

3.5.3. Палата белгече:

боерыкны яки баш тарту турында хатны терки.

мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итә, рәсмиләштерелгән күрсәтмә яки җир кишәрлеген төзүдән баш тарту турында хат бирү датасын һәм вакытын хәбәр итә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар Палата җитәкчесе тарафыннан документларга имза куелган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында хәбәр итү.

3.6. Гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү

3.6.1. Палата белгече кергән карар нигезендә:

җир кишәрлеген тапшыруга кабул итү - тапшыру акты проектын әзерли;

әзерләнгән документ проектын килештерә һәм имза кую өчен Палата җитәкчесенә җибәрә.

Баш тарту турында хат килгән очракта, әлеге Регламентның 3.6.4 пунктында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүчегә карар биргәннән соң ике көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: имза куюга юнәлдерелгән килешү проекты.

3.6.2. Палата җитәкчесе кабул итү-тапшыру актына имза куя һәм Милек мөнәсәбәтләре бүлегенә (алга таба – Бүлек) җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар алдагы процедураны тәмамлаганнан соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: имзаланган килешү.

3.6.3. Бүлек белгече:

мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итә, рәсмиләштерелгән күрсәтмә яки җир кишәрлеген төзүдән баш тарту турында хат бирү датасын һәм вакытын хәбәр итә.

теркәү журналында актны теркәп куя.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар Палата җитәкчесе тарафыннан документка кул куелган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәләре: гариза бирүчегә хәбәр итү.

3.6.4. Бүлек белгече гариза бирүчегә кабул итү-тапшыру актын имзасын куйдырып (под роспись) бирә.

Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарткан очракта мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хатны бирә яки почта аша җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гамәлгә ашырыла:

15 минут эчендә-гариза бирүче шәхсән килгән очракта;

әлеге Регламентның 3.6.1 пунктчасында каралган процедура тәмамланганнан соң, җавапны почта аша хат белән җибәргән очракта, бер көн эчендә.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән кабул итү-тапшыру акты яки почта аша җибәрелгән баш тарту турында хат.

3.7. Техник хаталарны төзәтү.

3.7.1. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булып торучы, документта техник хата ачыкланган очракта, гариза бирүче Палатага тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза (4нче кушымта);

техник хатасы булган, гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән, документ;

юридик көчкә ия, техник хаталар булуын таныклаучы, документлар.

Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдә техник хатаны төзәтү турында гаризаны мөрәҗәгать итүче (аның вәкиле) шәхсән үзе, яисә почта аша (шул исәптән электрон почта аша), йә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы яки КФҮ аша бирә.

3.7.2. Документларны кабул итү өчен җаваплы белгеч техник хаталарны төзәтү турында гариза кабул итә, кушып бирелгән документлар белән гаризаны терки һәм аларны Палатага тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгәннән соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Палата белгеченә карауга юнәлдерелгән кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

3.7.3. Палата белгече документларны карый һәм хезмәт нәтиҗәсе булган документка төзәтмәләр кертү максатларында әлеге Регламентның 3.5 пунктында каралган процедураларны гамәлгә ашыра, һәм төзәтелгән документны мөрәҗәгать итүченең (аның вәкиленең) шәхсән имзасы белән бирә техник хата булган документның оригиналын алып калу белән, яки мөрәҗәгать итүчегә почта аша (электрон почта аша) документ алу мөмкинлеге турында хат җибәрә Палатага техник хатасы булган документның оригиналын тапшырганда.

Әлеге пунктча белән билгеләнә торган процедура техник хатаны ачыклаганнан соң яки теләсә кайсы кызыксынган заттан җибәрелгән хата турында гариза алганнан соң өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән (җибәрелгән) документ.

## 4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту мөрәҗәгать итүчеләрнең хокукларын бозу очракларын ачыклау һәм бетерү, муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешен тикшерү, җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып торалар:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү буенча документлар проектларын тикшерү һәм килештерү. Тикшерү нәтиҗәсе булып, проектларны визалау тора;

2) эш башкаруны (делопроизводство) алып баруны тикшерүне билгеләнгән тәртиптә үткәрүләр;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешенә билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы (җирле үзидарә органының ярты еллык яки еллык эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр уздырганда муниципаль хезмәт күрсәтү белән бәйле барлык мәсьәләләр каралырга мөмкин (комплекслы тикшерүләр), яки мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча.

Агымдагы контроль максатларында мәгълүматларның электрон базасында булган белешмәләр, хезмәт корреспонденциясе, административ процедураларны

башкаручы белгечләрнең телдән һәм язма мәгълүматлары, тиешле документларны исәпкә алу журналлары һәм башка белешмәләр кулланыла.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләрнең башкарылуын контрольдә тоту өчен һәм карарлар кабул иткәндә Палата җитәкчесенә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр тапшырыла.

Белгечләр административ процедураларның срокларын, эзлеклелеген һәм эчтәлеген бозу очраклары һәм сәбәпләре турында кичекмәстән муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесенә хәбәр итәләр, шулай ук бозуларны бетерү буенча ашыгыч чаралар күрәләр

4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедуралар тарафыннан билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеген үтәүгә агымдагы контроль, муниципаль хезмәт күрсәтү буенча эшне оештыру өчен җаваплы, Палата җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары, шулай ук инфраструктура үсеше бүлеге белгечләре тарафыннан башкарыла.

4.3. Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар исемлеге җирле үзидарә органының структур бүлекчәләре турында нигезләмәләр һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәсендә мөрәҗәгать итүчеләрнең хокукларын бозу ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Җирле үзидарә органы җитәкчесе мөрәҗәгать итүчеләрнең мөрәҗәгатьләрен вакытында карап тикшермәгән өчен җаваплы.

Җирле үзидарә органының структур бүлекчәсе җитәкчесе (җитәкчесе урынбасары) әлеге Регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрне вакытында һәм (яки) тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплылык тота.

Муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмау) өчен вазыйфаи затлар һәм башка муниципаль хезмәткәрләр Законда билгеләнгән тәртиптә җаваплы.

4.5. Муниципаль хезмәт күрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан тикшереп тору муниципаль хезмәт күрсәткәндә җирле үзидарә органы эшчәнлегенең ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм ышанычлы мәгълүмат алу һәм муниципаль хезмәт күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге ярдәмендә гамәлгә ашырыла.

## 5. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә күрсәтелгән оешмаларның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм

**гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирүнең судка кадәр (судтан тыш) тәртибе**

5.1. Муниципаль хезмәт алучылар муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы Палата хезмәткәрләренең эш-гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр тәртиптә шикаять белдерү хокукына ия, Палатага яки муниципаль берәмлек Советына.

Мөрәҗәгать итүче шикаять белән мөрәҗәгать итә ала, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең соравын (запрос) теркәү срогы бозылганда;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын бозу;

3) мөрәҗәгать итүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Чирмешән муниципаль районының норматив хокукый актларында тәкъдим итү яисә гамәлгә ашыру каралмаган документларны яки мәгълүматны яисә гамәлләр башкаруны таләп итү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Чирмешән муниципаль районы норматив хокукый актларында бирү каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итүдән баш тарту;

5) әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда баш тарту нигезләре каралмаган булса, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту;

6) муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Чирмешән муниципаль районы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп итү;

7) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән опечаткаларны һәм хаталарны төзәтүдән Палатаның, Палата вазыйфаи затының баш тартуы яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срокларын бозу;

8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срокларын яки тәртибен бозу;

9) әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда туктатып тору нигезләре каралмаган булса, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору;

10) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен, яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдә кирәкле документларны кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканда булмавы һәм (яисә) дөреслеге күрсәтелмәгән документларның яисә белешмәләрнең мөрәҗәгать итүчедән муниципаль хезмәт күрсәткәндә таләп итү, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш.

5.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, муниципаль хезмәткәрнең, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять язмача кәгазьдә яки электрон формада бирелә.

Шикаять почта аша, КФҮ аша, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен, Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтын (http://www.cheremshan.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталын (http://uslugi.tatar.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталын (http://www.gosuslugi.ru/) кулланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхси кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин.

5.3. Органга кергән шикаять гариза кергән вакыттан алып бер көн эчендә теркәлә.Электрон рәвештә кергән шикаять ял (бәйрәм) көнендә ял (бәйрәм) көненнән соң килә торган эш көнендә теркәлә.

Муниципаль хезмәт күрсәтүче органга яисә югары органга (булган очракта) кергән шикаять, аны теркәгәннән соң унбиш эш көне эчендә карап тикшерелергә тиеш, ә муниципаль хезмәт күрсәтүче органга шикаять биргән очракта, мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тарткан очракта йә җибәрелгән опечаткаларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тарткан очракта яисә мондый төзәтмәләрнең билгеләнгән срогы бозылуга карата шикаять белдерелгән очракта - аны теркәгән көннән биш эш көне эчендә.

5.4. Шикаять түбәндәге мәгълүматны тупларга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган хезмәт күрсәтүче органның, хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи заты яисә муниципаль хезмәткәрнең исеме;

2) гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта), мөрәҗәгать итүченең - физик затның яшәү урыны турында мәгълүматлар, йә мөрәҗәгать итүченең - юридик затның атамасы, урнашу урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи заты яисә муниципаль хезмәткәрнең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

4) мөрәҗәгать итүченең хезмәт күрсәтүче органның, хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең карары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән килешмәгән дәлилләре.

5.5. Шикаятькә, шикаятьтә бәян ителгән шартларны раслый торган, документларның күчермәләре дә кушылырга мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа кушып бирелә торган документлар исемлеге китерелә.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән, кабул ителгән карарны юкка чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм опечаткаларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия

Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда алынуы каралмаган акчаларны кире кайтару рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килә торган көннән дә соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача һәм мөрәҗәгать итүче теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында мотивлаштырылган җавап җибәрелә.

5.7. Шикаятьне канәгатьләндерелергә тиешле дип тану очрагында, мөрәҗәгать итүчегә җавапта, муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларында, Палата тарафыннан башкарыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенәләр һәм муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында мөрәҗәгать итүчегә кирәкле алга таба гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә җавап итеп, кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яки нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составының билгеләре билгеләнгән очракта, шикаятьләрне карау буенча вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрәләр.

## 6. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә административ процедураларны (гамәлләрне) үтәү үзенчәлекләре

6.1. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелеген тасвирлау түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запросларны формалаштыру һәм җибәрү, шул исәптән комплекслы ведомствоара запрос буенча;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза биргәндә файдаланылган мөрәҗәгать итүченең көчәйтелгән квалификацияле цифрлы электрон имзасының чынбарлыгын тикшерү;

5) документлар белән гаризаны Палатага җибәрү;

6) гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәсен бирү.

6.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү

Мөрәҗәгать итүче КФҮгә муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында консультацияләр алу өчен шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

КФҮ (МФЦ) белгече гариза бирүчегә хәбәр итә, шул исәптән муниципаль хезмәт алу өчен тәкъдим ителә торган документларның составы, формасы һәм башка сораулар буенча да, кирәк булганда гариза бланкын тутыруда ярдәм итә.

Гариза бирүче КФҮ сайтыннан http://mfc16.tatarstan.ru/ ирекле файдалану юлы белән муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат алырга мөмкин

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар мөрәҗәгать итүченең мөрәҗәгате көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм муниципаль хезмәт күрсәтүнең башка мәсьәләләре буенча мәгълүмат.

6.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

6.3.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән үзе, ышанычлы зат аша яисә электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтү турында язмача гариза бирә һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә КФҮ (МФЦ), КФҮнең читтән торып эш урынына документларны тапшыра.

Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза электрон формада Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша җибәрелә. Электрон формада алынган гаризаны теркәү билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

6.3.2. Гаризалар кабул итә торган КФҮ белгече, КФҮ эше регламентында каралган процедураларны, гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар КФҮ эше регламентында билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

6.4. Документлар пакетын формалаштыру

6.4.1. КФҮ белгече КФҮ эше регламенты нигезендә:

мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза биргәндә файдаланылган көчәйтелгән квалификация санлы электрон имзасының чынбарлыгын тикшерә;

муниципаль хезмәт күрсәтүдә, шул исәптән комплекслы ведомствоара соратып алу буенча да, катнашучы органнарга ведомствоара запросларны формалаштыра һәм җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар, КФҮ эше регламентында билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: җибәрелгән запрослар.

6.4.2. КФҮ белгече сорауларга җаваплар алгач, документлар пакетын формалаштыра һәм аны Палатага КФҮнең эш Регламентында билгеләнгән тәртиптә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар, КФҮ эше регламентында билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Палатага җибәрелгән документлар.

6.5. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү

6.5.1. КФҮ белгече муниципаль хезмәт нәтиҗәсен Палатадан алганда аны билгеләнгән тәртиптә терки. мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында хәбәр итә.

Әлеге пунктча белән билгеләнә торган процедуралар Палатадан документлар кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында хәбәр итү.

6.5.2. КФҮ белгече мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирә

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар чират тәртибендә, КФҮ эше регламентында билгеләнгән срокларда мөрәҗәгать итүче килү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: муниципаль хезмәтнең бирелгән нәтиҗәсе.

1нче Кушымта

Россия Федерациясе Җир кодексыннан өземтә

39.5. Статья. Дәүләт яки муниципаль милектә булган җир кишәрлеген гражданга яки юридик затка милеккә бушлай бирү очраклары

Дәүләт яки муниципаль милектә булган җир кишәрлеген гражданга яки юридик затка вәкаләтле орган карары нигезендә милеккә бушлай бирү түбәндәгеләр бирелгән очракта гамәлгә ашырыла:

1) төзелеш территориясе чикләрендә төзелгән, аңа карата аны үстерү турында шартнамә төзелгән җир кишәрлеген әлеге шартнамә төзелгән затка;

2) җир кишәрлеген, мондый җир кишәрлегендә урнашкан дини яки хәйрия әһәмиятендәге биналар яки корылмалары милкендә булган дини оешмага;

3) гражданнар тарафыннан төзелгән коммерциячел булмаган оешмага бирелгән бакчачылыкны, яшелчәчелекне алып бару өчен һәм әлеге коммерциягә карамаган оешманың гомуми файдалanudагы милкенә караучы җир кишәрлеген бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килгән җир кишәрлеген яки федераль законда каралган очракларда, әлеге коммерциячел булмаган оешма әгъзаларының гомуми милкенә;

4) җир кишәрлеген гражданга, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.10 статьясындагы 2 пунктының 6 пунктчасы нигезендә җир кишәрлеген аңа түләүсез файдалануга биргән көннән соң биш ел уткәч, әлеге граждан мондый җир кишәрлеген күрсәтелгән чорда билгеләнгән рөхсәт ителгән файдалану нигезендә файдаланган очракта;

5) җир кишәрлеген гражданга, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.10 статьясындагы 2 пунктының 7 пунктчасы нигезендә җир кишәрлеген аңа түләүсез файдалануга биргән көннән соң биш ел уткәч, әлеге граждан мондый җир кишәрлеген күрсәтелгән чорда билгеләнгән рөхсәт ителгән файдалану нигезендә файдаланган һәм Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән муниципаль берәмлектә төп эш урыны буенча һәм белгечлек буенча эшләгән очракта;

6) өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнарга Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары билгеләгән очракта һәм тәртиптә җир кишәрлеге. Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары мондый гражданнар торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәптә торырга тиеш яисә мондый гражданнарның аларны әлеге исәпкә кую өчен нигезләре бар дигән таләпне күздә тотарга мөмкин, шулай ук мондый гражданнарга, аларның ризалыгы белән, җир кишәрлеген милеккә бушлай бирүгә алмашка торак урыннары белән тәэмин итү буенча башка социаль ярдәм чараларын бирү мөмкинлеген билгели ала;

7) җир кишәрлеген әлеге статьяның 6 пунктчасында күрсәтелмәгән башка гражданнарның аерым категорияләренә һәм (яисә) гражданнар төзегән коммерциячел булмаган оешмаларга, федераль законнарда каралган очракларда, Россия Федерациясе субъектлары законнарында каралган очракларда, гражданнарның аерым категорияләренә;

8) дини оешмага даими (сроксыз) файдалану хокукында бирелгән һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен билгеләнгән җир кишәрлеген, бу оешмага Россия Федерациясе субъектлары законнарында каралган очракларда.

2нче Кушымта

______________________________________________
(муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы исеме)

______________________________________________
(физик затлар өчен-фамилиясе, исеме, атасының исеме (булса), яшәү урыны, шәхесне раслаучы документ реквизитлары, ИНН)

______________________________________________
(юридик затлар өчен-атамасы, урнашу урыны, оештыру-хокукый формасы, ЕГРЮЛда, ОГРНда дәүләт теркәве турында белешмәләр)

______________________________________________
(почта адресы, электрон почта адресы, элемтә өчен телефон номеры)

## Җир кишәрлеген милеккә бушлай бирү турында гариза

_____________________________________________ нигезендә сорыйм сезне,
(ЗК РФ 39.5 ст. каралган саннан нигез күрсәтелә).
___________________________________________________________өчен бирергә
(җир кишәрлеген файдалану максаты күрсәтелә)
___________ кв.м. мәйданлы җир кишәрлеген, рөхсәт ителгән куллану төре белән ___________________, _______________ җир категориясеннән, киләсе адрес буенча урнашкан: ___________ муниципаль районы (шәһәр округы), _________________ торак пункты _________________урамы ________йорт, даими (сроксыз) файдалануга, сатулар үткәрмичә.

Өстәмә белешмәләр (түбәндәге шартлар булганда тутырыла):

__________________________________________________________________________
дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен җир кишәрлеген алу турында карар реквизитлары, әгәр дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлеге урынына җир кишәрлеге бирелгән очракта;

__________________________________________________________________________
территориаль планлаштыру документын һәм (яки) территорияне планлаштыру проектын раслау турындагы карар реквизитлары, әгәр җир участогы әлеге документта һәм (яки) әлеге проектта каралган объектларны урнаштыру өчен бирелгән булса;

__________________________________________________________________________
дәгъва белдерелә торган җир кишәрлеге барлыкка килгән яисә аның чикләре әлеге карар нигезендә төгәлләштерелгән очракта, җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында карар реквизитлары.

Гаризага түбәндәге документлар (сканкопияләр) теркәлә:

Физик затлар:

1) Шәхесне раслаучы документ күчермәсе (гражданин өчен);

2) Вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ (әгәр мөрәҗәгать итүче исеменнән вәкил гамәл кылса);

3) Территориянең кадастр планында җир кишәрлегенең расланган урнашу схемасы (әгәр сорала торган җир кишәрлеген төзергә кирәк булса һәм чикләрендә җир кишәрлеге төзергә кирәк булачак территорияне ызанлау проекты расланмаган булса);

Юридик затлар:

1) Вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ (әгәр мөрәҗәгать итүче исеменнән вәкил гамәл кылса);

2) Территориянең кадастр планында җир кишәрлегенең расланган урнашу схемасы (әгәр сорала торган җир кишәрлеген төзергә кирәк булса һәм чикләрендә җир кишәрлеге төзергә кирәк булачак территорияне ызанлау проекты расланмаган булса);

*Үз ризалыгымны, шулай ук мин тәкъдим иткән затның ризалыгын белдерәм шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә (җыю, системалаштыру, туплау, саклау, төгәлләштерү (яңарту, үзгәртү), куллану, тарату (шул исәптән тапшыру), персональ мәгълүматларны зарарсызлау, блоклау, юк итү, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында персональ мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәк булган башка гамәлләр), шул исәптән автоматлаштырылган режимда, алар нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан карарлар кабул итүне дә кертеп, муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында.*

*Әлеге белән раслыйм: гаризага кертелгән, минем шәхесемә һәм мин тәкъдим иткән затка караган, шулай ук минем тарафтан түбәнрәк кертелгән мәгълүматларның дөрес булуын. Гаризага кушып бирелгән документлар (документларның сканкопияләре) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләргә туры килә, гариза тапшырган вакытта бу документлар гамәлдә һәм дөрес мәгълүматларга ия.*

_________________________._________________________*телефоны аша миңа тәкъдим ителгән муниципаль хезмәтнең сыйфатын бәяләү буенча сораштыруда катнашырга ризалык бирәм.*

| | | |
|---|---|---|
| __________________ | ____________ | __________________________________ |
| (дата) | (имза) | (Фамилия, исем, этисенең исеме) |

3нче Кушымта

**Мөрәҗәгать итүченең җир кишәрлеген торглар үткәрмичә сатып алуга хокукын раслый торган документлар исемлегеннән өземтә**

(Россия Икътисадый үсеш министрлыгының
2015 елның 12 гыйнварындагы 1нче номерлы боерыгына кушымта)

| № п/п | Сатулар үткәрмичә генә җир кишәрлеге бирү нигезе | Җир кишәрлеген түләүсез яисә түләүле бирү гамәлгә ашырыла торган хокук төре | Мөрәҗәгать итүче | Җир кишәрлеге | Мөрәҗәгать итүченең җир кишәрлеген сату үткәрмичә алу хокукын раслаучы һәм җир кишәрлегенә хокуклар алу турында гаризага кушып бирелә торган документлар <1> |
|---|---|---|---|---|---|
| 11. | Җир кодексының 39.5 статьясындагы 1 пунктчасы | Милеккә бушлай | Төзелгән территорияне үстерү турында шартнамә төзелгән зат | Аны үстерү турында шартнамә төзелгән, төзелеш территориясе чикләрендә төзелгән җир кишәрлеге | Төзелгән территорияне үстерү турында килешү<br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир кишәрлеге турында) ЕГРН дан өземтә<br>* Расланган планлаштыру проекты һәм территорияне межалау буенча расланган проект<br>* Мөрәҗәгать итүче булып торучы юридик зат |

| № п/п | Сатулар уткәрмичә генә җир кишәрлеге бирү нигезе | Җир кишәрлеген түләүсез яисә түләүле бирү гамәлгә ашырыла торган хокук төре | Мөрәҗәгать итүче | Җир кишәрлеге | Мөрәҗәгать итүченең җир кишәрлеген сату уткәрмичә алу хокукын раслаучы һәм җир кишәрлегенә хокуклар алу турында гаризага кушып бирелә торган документлар <1> |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | турында ЕГРЮЛдан өземтә |
| 12. | Җир кодексының 39.5 статьясындагы 2 пунктчасы | Милеккә бушлай | Милкендә дини яки хәйрия билгеләнешендәге бинаалары яки корылмалары булган дини оешма | Дини яки хәйрия билгеләнешендәге бинаалар яки корылмалар урнашкан җир кишәрлеге | Гариза бирүченең бинага, корылмага хокукын раслаучы (билгеләүче) документ,әгәр мондый бинага, корылмага хокук ЕГРНда теркәлмәгән булса<br><br>Гариза бирүченең соралган җир кишәрлегенә хокукын раслаучы (билгеләүче) документ, әгәр мондый җир кишәрлегенә хокук ЕГРНда теркәлмәгән булса (җир кишәрлегенә тиешле хокуклар булганда)<br><br>Мөрәҗәгать итүченең (мөрәҗәгать итүчеләрнең) сорала торган җир кишәрлегендә урнашкан |

| № п/п | Сатулар үткәрмичә генә җир кишәрлеге бирү нигезе | Җир кишәрлеген түләүсез яисә түләүле бирү гамәлгә ашырыла торган хокук төре | Мөрәҗәгать итүче | Җир кишәрлеге | Мөрәҗәгать итүченең җир кишәрлеген сату үткәрмичә алу хокукын раслаучы һәм җир кишәрлегенә хокуклар алу турында гаризага кушып бирелә торган документлар <1> |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | барлык биналар, корылмалар исемлеген, кадастр (шартлы, инвентарь) номерларын һәм тиешле хокукта мөрәҗәгать итүченеке булган биналарның, корылмаларның адреслы ориентирларын күрсәтеп, хәбәрнамәсе<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир кишәрлеге турында) ЕГРН дан өземтә<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (соралган җир кишәрлегендә урнашкан бина һәм (яки) корылма турында) ЕГРН дан |

| № п/п | Сатулар үткәрмичә генә җир кишәрлеге бирү нигезе | Җир кишәрлеген түләүсез яисә түләүле бирү гамәлгә ашырыла торган хокук төре | Мөрәҗәгать итүче | Җир кишәрлеге | Мөрәҗәгать итүченең җир кишәрлеген сату үткәрмичә алу хокукын раслаучы һәм җир кишәрлегенә хокуклар алу турында гаризага кушып бирелә торган документлар <1> |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | өземтә<br>* Мөрәҗәгать итүче булып торучы юридик зат турында ЕГРЮЛдан өземтә |
| 13. | Җир кодексының 39.5 статьясындагы 3 пунктчасы | Милеккә бушлай | Бакчачылык, яшелчәчелек өчен җир кишәрлеге бирелгән гражданнар тарафыннан төзелгән коммерцияле булмаган оешма | Бакчачылык, яшелчәчелек алып бару өчен гражданнар тарафыннан төзелгән коммерциячел булмаган оешмага бирелгән җир кишәрлеген бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килгән һәм коммерциячел булмаган | Җир кишәрлеге алу турында коммерциячел булмаган оешма органы карары<br>* Территорияне межалауның расланган проекты<br>* Коммерциягә карамаган берләшмә территориясен оештыру һәм төзү проекты (территорияне ызанлауның расланган проекты булмаган очракта) |

| № п/п | Сатулар үткәрмичә генә җир кишәрлеге бирү нигезе | Җир кишәрлеген түләүсез яисә түләүле бирү гамәлгә ашырыла торган хокук төре | Мөрәҗәгать итүче | Җир кишәрлеге | Мөрәҗәгать итүченең җир кишәрлеген сату үткәрмичә алу хокукын раслаучы һәм җир кишәрлегенә хокуклар алу турында гаризага кушып бирелә торган документлар <1> |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | оешманың гомуми файдаланудагы милкенә караган җир кишәрлеге | * Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир кишәрлеге турында) ЕГРН дан өземтә<br><br>* Мөрәҗәгать итүче булып торучы юридик зат турында ЕГРЮЛдан өземтә |
| 14. | Җир кодексының 39.5 статьясындагы 3 пунктчасы | Гомуми милеккә бушлай | Бакчачылык, яшелчәчелек өчен җир кишәрлеге бирелгән гражданнар тарафыннан төзелгән коммерцияле булмаган оешма әгъзалары | Бакчачылык, яшелчәчелек алып бару өчен гражданнар тарафыннан төзелгән коммерциячел булмаган оешмага бирелгән җир кишәрлеген бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килгән | Мөрәҗәгать итүченең коммерциягә карамаган оешмада әгъзалыгын раслый торган документ<br><br>* Территорияне межалауның расланган проекты<br><br>* Коммерциягә карамаган берләшмә территориясен оештыру һәм төзү проекты (территорияне |

| № п/п | Сатулар үткәрмичә генә җир кишәрлеге бирү нигезе | Җир кишәрлеген түләүсез яисә түләүле бирү гамәлгә ашырыла торган хокук төре | Мөрәҗәгать итүче | Җир кишәрлеге | Мөрәҗәгать итүченең җир кишәрлеген сату үткәрмичә алу хокукын раслаучы һәм җир кишәрлегенә хокуклар алу турында гаризага кушып бирелә торган документлар <1> |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | һәм коммерциячел булмаган оешманың гомуми файдаланудагы милкенә караган җир кишәрлеге | ызанлауның расланган проекты булмаган очракта)<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир кишәрлеге турында) ЕГРН дан өземтә<br><br>* Граждан әгъзасы булган коммерциягә карамаган оешма турында ЕГРЮЛдан өземтә |
| 15. | Җир кодексының 39.5 статьясындагы 4 пунктчасы | Милеккә бушлай | Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен алты елдан артмаган срокка түләүсез файдалануга җир кишәрлеге бирелгән граждан яки Россия Федерациясе субъекты законы | Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен яисә крестьян (фермер) хуҗалыгы эшчәнлеген башкару өчен билгеләнгән һәм | * Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир кишәрлеге турында) ЕГРН дан өземтә |

| № п/п | Сатулар уткәрмичә генә жир кишәрлеге бирү нигезе | Жир кишәрлеген түләүсез яисә түләүле бирү гамәлгә ашырыла торган хокук төре | Мөрәжәгать итүче | Жир кишәрлеге | Мөрәжәгать итүченең жир кишәрлеген сату уткәрмичә алу хокукын раслаучы һәм жир кишәрлегенә хокуклар алу турында гаризага кушып бирелә торган документлар <1> |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | белән билгеләнгән муниципаль берәмлек территориясендә крестьян (фермер) хуҗалыгы тарафыннан эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен | рөхсәт ителгән куллану нигезендә биш елдан артык файдаланыла торган жир кишәрлеге | |
| 16. | Жир кодексының 39.5 статьясындагы 5 пунктчасы | Милеккә бушлай | Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән белгечлек буенча муниципаль берәмлекләрдә төп эш урыны буенча эшләүче граждан | Шәхси торак төзелеше яисә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен билгеләнгән, Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән муниципаль берәмлектә | Эшкә алу турында боерык, хезмәт кенәгәсеннән өземтә яки хезмәт килешүе (контракт)<br>* Кучемсез милек объекты турында (сорала торган жир кишәрлеге турында) ЕГРН дан өземтә |

| № п/п | Сатулар үткәрмичә генә җир кишәрлеге бирү нигезе | Җир кишәрлеген түләүсез яисә түләүле бирү гамәлгә ашырыла торган хокук төре | Мөрәҗәгать итүче | Җир кишәрлеге | Мөрәҗәгать итүченең җир кишәрлеген сату үткәрмичә алу хокукын раслаучы һәм җир кишәрлегенә хокуклар алу турында гаризага кушып бирелә торган документлар <1> |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | урнашкан җир кишәрлеге | |
| 17. | Җир кодексының 39.5 статьясындагы 6 пунктчасы | Милеккә бушлай | Өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнар | Җир кишәрлекләрен бирү очраклары Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнә | Россия Федерациясе субъектлары законнары нигезендә җир кишәрлекләре бирү шартларын раслаучы документлар<br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир кишәрлеге турында) ЕГРН дан өземтә |
| 18. | Җир кодексының 39.5 статьясындагы 7 пунктчасы | Милеккә бушлай | Федераль закон белән билгеләнә торган, гражданнарның аерым категорияләре һәм (яисә) гражданнар | Җир кишәрлекләрен бирү очраклары федераль закон белән билгеләнә | Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән, җир кишәрлеген сатып алу хокукын раслый торган документлар<br>* Күчемсез милек |

| № п/п | Сатулар үткәрмичә генә җир кишәрлеге бирү нигезе | Җир кишәрлеген түләүсез яисә түләүле бирү гамәлгә ашырыла торган хокук төре | Мөрәҗәгать итүче | Җир кишәрлеге | Мөрәҗәгать итүченең җир кишәрлеген сату үткәрмичә алу хокукын раслаучы һәм җир кишәрлегенә хокуклар алу турында гаризага кушып бирелә торган документлар <1> |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | тарафыннан төзелгән коммерциячел булмаган оешмалар | | объекты турында (сорала торган җир кишәрлеге турында) ЕГРН дан өземтә |
| 19. | Җир кодексының 39.5 статьясындагы 7 пунктчасы | Милеккә бушлай | Гражданнарның Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнә торган аерым категорияләре | Җир кишәрлекләрен бирү очраклары Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнә | Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән җир кишәрлеген сатып алу хокукын раслый торган документлар |
| 20. | Җир кодексының 39.5 статьясындагы 8 пунктчасы | Милеккә бушлай | Даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында һәм авыл хуҗалыгы житештерүе өчен билгеләнгән җир кишәрлеге булган дини оешма | Җир кишәрлекләрен бирү очраклары Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнә | Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән җир кишәрлеген сатып алу хокукын раслый торган документлар |

<1> Документлар төп нөсхәдә (күчермәсендә, әгәр документлардан һәркем файдалана алырлык булса) йә җир кишәрлегенә хокук алу турында гариза кабул итүче башкарма хакимият органының яки җирле үзидарә органының вазыйфаи заты таныклый торган күчермәләрендә тапшырыла (җибәрелә).

<2> Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2001, N 44, 4147 ст.; 2014, N 26, 3377 ст.

<3> "*"Символы белән билгеләнгән документлар дәүләт яки муниципаль милектә булган җир кишәрлекләре белән идарә итүгә вәкаләтле орган (алга таба - вәкаләтле орган) белән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек аша соратып алына. Күчемсез милек объекты (сорала торган җир участогы турында) турында ЕГРН дан өземтә җир кишәрлегенә хокуклар алу турында гаризага беркетелми һәм соралган җир участогын төзергә кирәк булган очракта, җир кишәрлеге бирүне алдан килештереп, җир кишәрлеге биргәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек аша вәкаләтле орган тарафыннан соратып алынмый. Әгәр бинага, корылмага, төзелеп бетмәгән төзелеш объектына хокук федераль закон нигезендә, әлеге хокукны ЕГРНда дәүләт теркәвенә алу мизгеленә карамастан, барлыкка килгән дип санала икән, күчемсез милек объекты (соратып алына торган җир кишәрлегендә урнашкан бина, корылма яки төзелеп бетмәгән объект турында) турында ЕГРНдан өземтә җир кишәрлегенә хокуклар алу турындагы гаризага кушылмый һәм вәкаләтле орган тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек аша соратып алынмый.

4нче Кушымта

Татарстан Республикасы
_________муниципаль районының
Мөлкәт һәм җир
мөнәсәбәтләре палатасы
Рәисенә:
_____________________________
(кемнән)

**Техник хатаны төзәтү турында**
**гариза**

Муниципаль хезмәт күрсәтүдә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм ___________________________________________________________________________

(хезмәт күрсәтү атамасы)

Язылган:_____________________________________________________________
_____________________________________________________________________

Дөрес мәгълүматлар:___________________________________________________
_____________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүегезне һәм муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүегезне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.

2.

3.

Техник хаталарны төзәтү турында гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта, мондый карарны җибәрүегезне сорыйм:

электрон документ юллау юлы белән E-mail адресына:_______;

кәгазьдә расланган күчермә рәвешендә почта аша түбәндәге адрес буенча: _________________________________________________________________.

Үз ризалыгымны, шулай ук мин тәкъдим иткән затның ризалыгын белдерәм шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә (җыю, системалаштыру, туплау, саклау, төгәлләштерү (яңарту, үзгәртү), куллану, тарату (шул исәптән тапшыру), персональ мәгълүматларны зарарсызлау, блоклау, юк итү, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында персональ мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәк булган башка гамәлләр), шул исәптән автоматлаштырылган режимда, алар нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан карарлар кабул итүне дә кертеп, муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында.

Әлеге белән раслыйм: гаризага кертелгән, минем шәхесемә һәм мин тәкъдим

иткән затка караган, шулай ук минем тарафтан түбәнрәк кертелгән мәгълүматларның дөрес булуын раслыйм. Гаризага кушып бирелгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләргә туры килә, гариза тапшырган вакытта бу документлар гамәлдә һәм дөрес мәгълүматларга ия.

________________________телефоны аша миңа тәкъдим ителгән муниципаль хезмәтнең сыйфатын бәяләү буенча сораштыруда катнашырга ризалык бирәм.

_______________ __________________ ( _________________)

(дата) (имза) (Фамилия, исем, әтисенең исеме)

Кушымта
(белешмә)

**Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм аның үтәлешен контрольдә тотучы вазыйфаи затлар реквизитлары,**

**Чирмешән муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Палата рәисе | 2-58-30 | Inna.Taydakova@tatar.ru |
| Палата белгече | 2-57-11<br>2-51-93 | Kozlova.T@tatar.ru |

**Чирмешән муниципаль районы Советы**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башлык | 2-59-00 | Ferdinat.Davletshin@tatar.ru |